ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

14.12.2023 г. Казань № 667-96/тэ-2023

Җылылык энергиясе чыганаклары коллекторларында электр энергиясен җитештерү буенча генерацияләү куәте 25 мегаватт һәм аннан күбрәк булган «Түбән Кама ҖЭҮ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең җылылык энергиясе чыганагында электр һәм җылылык энергиясен катнаш эшләп чыгару режимында җитештерелә торган җылылык энергиясенә 2024-2028 елларга тарифлар билгеләү турында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя билгеләү турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләрне (тарифларны) хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 14.12.2023 №58-ПР утырыш беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Җылылык энергиясе чыганаклары коллекторларында электр энергиясен җитештерү буенча генерацияләү куәте 25 мегаватт һәм аннан күбрәк булган «Түбән Кама ҖЭҮ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең (алга таба – «Түбән Кама ҖЭҮ» ҖЧҖ) җылылык энергиясе чыганагында электр һәм җылылык энергиясен катнаш эшләп чыгару режимында җитештерелә торган җылылык энергиясенә әлеге карарның 1 нче кушымтасына туры китереп, календарь буенча бүленгән тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2024 елның 1 гыйнварыннан 2028 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Әлеге карарның 2 кушымтасы нигезендә 2024-2028 елларга, билгеләнгән тарифларны индексацияләү ысулыннан файдаланып, тарифлар формалаштыру

өчен җайга салуның озак сроклы чорына билгеләнә торган озак сроклы җайга салу параметрларын билгеләргә.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
14.12.2023 № 667-96/тэ-2023
карарына 1 нче кушымта

# Җылылык энергиясе чыганаклары коллекторларында электр энергиясен җитештерү буенча генерацияләү куәте 25 мегаватт һәм аннан күбрәк булган «Түбән Кама ҖЭҮ» ҖЧҖ җылылык энергиясе чыганагында электр һәм җылылык энергиясен катнаш эшләп чыгару режимында җитештерелә торган җылылык энергиясенә 2024-2028 елларга календарь буенча бүленгән тарифлар

| т/с | Җайга салынулы оешманың исеме | Тариф төре | Ел | Су | Басым астында сайланма пар | | | | Әче һәм редукцияләштерүче пар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 1,2 башлап 2,5 кг/см$^2$ кадәр | 2,5 башлап 7,0 кг/см$^2$ кадәр | 7,0 башлап 13,0 кг/см$^2$ кадәр | югары 13,0 кг/см$^2$ | |
| Түбән Кама муниципаль районы | | | | | | | | | |
| 1 | «Түбән Кама ҖЭҮ» ҖЧҖ | Бер ставкалы тариф сум/Гкал | 01.01.2024 башлап 30.06.2024 кадәр | 736,13 | - | - | - | - | - |
| | | | 01.07.2024 башлап 31.12.2024 кадәр | 791,69 | - | - | - | - | - |
| | | | 01.01.2025 башлап 30.06.2025 кадәр | 791,69 | - | - | - | - | - |
| | | | 01.07.25 башлап 31.12.2025 кадәр | 871,15 | - | - | - | - | - |
| | | | 01.01.2026 башлап 30.06.2026 кадәр | 871,15 | - | - | - | - | - |
| | | | 01.07.2026 башлап 31.12.2026 кадәр | 895,05 | - | - | - | - | - |
| | | | 01.01.2027 башлап 30.06.2027 кадәр | 895,05 | - | - | - | - | - |
| | | | 01.07.2027 башлап 31.12.2027 кадәр | 953,03 | - | - | - | - | - |
| | | | 01.01.2028 башлап 30.06.2028 кадәр | 953,03 | - | - | - | - | - |
| | | | 01.07.2028 башлап 31.12.2028 кадәр | 967,78 | - | - | - | - | - |

Искәрмә. 1 Гкал энергиясенә кертелгән, су сыйфатында «Түбән Кама ҖЭҮ» ҖЧҖ җылылык энергиясе чыганагыннан җибәрелә торган ягулык чыгымнарның зурлыклары:

сум/Гкал

| т/с | Җайга салынулы оешманың аталышы | Ел | Су | Басым астында сайланма пар | | | | Әче һәм редукцияләнгән пар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 1,2 башлап 2,5 кг/см$^2$ кадәр | 2,5 башлап 7,0 кг/см$^2$ кадәр | 7,0 башлап 13,0 кг/см$^2$ кадәр | 13,0 кг/см$^2$ югары | |
| 1 | «Түбән Кама ҖЭҮ» ҖЧҖ | 01.01.2024 башлап 30.06.2024 кадәр | 668,49 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2024 башлап 31.12.2024 кадәр | 741,77 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2025 башлап 30.06.2025 кадәр | 749,45 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.25 башлап 31.12.2025 кадәр | 860,16 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2026 башлап 30.06.2026 кадәр | 797,42 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2026 башлап 31.12.2026 кадәр | 860,16 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2027 башлап 30.06.2027 кадәр | 829,31 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2027 башлап 31.12.2027 кадәр | 894,57 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2028 башлап 30.06.2028 кадәр | 862,49 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2028 башлап 31.12.2028 кадәр | 930,35 | - | - | - | - | - |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
14.12.2023 № 667-96/тэ-2023
карарына 2 нче кушымта

Билгеләнгән тарифларны индексацияләү ысулыннан файдаланып тарифлар формалаштыру өчен 2024-2028 елларга җайга салуның озак сроклы чорына билгеләнә торган озак сроклы җайга салу параметрлары

| т/с | Җайга салынулы оешманың аталышы | Ел | Операция чыгымнарының база дәрәҗәсе | Операция чыгымнарының нәтиҗәлелек индексы | Норматив табыш дәрәҗәсе | Җылылык белән тәэмин итүнең ышанычлылык дәрәҗәсе | Энергияне саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | Ягулык чыгымнарын үзгәртү динамикасы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | мең сум | % | % | Билгеләнгән куәтнең 1 Гкал/сәг өчен җылылык энергиясе чыганакларында технологик хилафлыклар нәтиҗәсендә җылылык энергиясен бирүне туктатып торулар саны | Җылылык энергиясе чыганаклары коллекторларыннан җибәрелә торган җылылык энергиясе берәмлеген җитештерүгә чыгымның чагыштырма чыгымы, кг/Гкал | |
| 1 | «Түбән Кама ҖЭҮ» ҖЧҖ | 2024 | 400 088,70 | х | х | 0 | х | х |
| | | 2025 | х | 1 | х | 0 | х | х |
| | | 2026 | х | 1 | х | 0 | х | х |
| | | 2027 | х | 1 | х | 0 | х | х |
| | | 2028 | х | 1 | х | 0 | х | х |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф карарларын кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге